| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2022 г.Лениногорск № 27

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2009 елның 23 октябрендәге 54 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2009 елның 23 октябрендәге 54 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 6 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац белән тулыландырыргаә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга;

б) 20 статьяның унбишенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы финанс елы башына район бюджеты акчаларының калдыклары:

хисап финанс елында файдаланылмый торган муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә, шулай ук район Советының хокукый акты белән билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында, финанс тәэминаты чыганагы булып күрсәтелгән субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле булган әлеге максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә, бюджет турындагы карарда каралган очракларда, вакытлыча касса өзеклекләрен каплауга һәм район исеменнән төзелгән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүгә муниципаль контрактлар шартлары нигезендә хисап финанс елында түләнергә тиешле муниципаль контрактлар, хисап финанс елында бирелгән юридик затларга субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелергә мөмкин;

хисап финанс елында Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бурыч тотрыклылыгы югары яки уртача дәрәҗәсе булган заемчылар төркеменә кертелгән бюджет ассигнованиеләрен тулысынча куллануга бәйле рәвештә барлыкка килгән калдыклар арасындагы аермадан артмаган күләмдә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясындагы 3 өлешенен икенче абзацында каралган бюджет ассигнованиеләрен арттыру суммасында район Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кулланыла; (бурыч тотрыклылыгы югары яки уртача булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлеккә кагылышлы өлешендә абзацның гамәле 2023 елның 1гыйнварына кадәр туктатылды);

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кертелгән бурыч алуларының гомуми суммасыннан артып киткән күләмдә җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән чараларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы йомгаклары буенча районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артып киткән күләмдә агымдагы финанс елында районның бурыч йөкләмәләрен кыскартучы түләүләрне гамәлгә ашыруга җибәрелә.» (абзацның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатылды);

в) 21 статьяда:

унөченче абзацта «муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «,муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләренә алмаштырырга;

унтугызынчы абзацта «чагылдырылган муниципаль гарантияләр буенча» сүзләреннән соң «,чагылдырылган муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган.» сүзләре белән алмаштырырга;

егерме өченче абзацны төшереп калдырырга;

г) 25 статьяның 2 өлешендә «,һәм Районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел

ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

д) 25 статьяның 3 өлешендә «һәм Районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен» сүзләреннән соң «,инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләре белән тулыландырырга.

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск
муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов